Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының ундүртенче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2018 елның 1 октябре № 105

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктына, Питрәч авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Питрәч авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге 104 номерлы “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” һәм Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетының “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 31 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган алдагы сорауны расларга: “2019 елда яшәү урыны Питрәч авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Питрәч авылында тротуарлар төзү;
- Олан Иле авылында балалар мәйданчыгы төзү;
- Шихазда авыл эчендәге юлларны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны “Вперёд” (“Алга”) район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Питрәч авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Рафиков